**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге Иске Татар Әмзәсе авылы торак пункты гражданнар җыены КАРАРЫ**

«24» октябрь 2024 ел № 6

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Әмзә авыл җирлеге Иске Татар Әмзәсе авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Әмзә авыл җирлеге Иске Татар Әмзәсе авылында яшәүче, 1 гр инвалидлардан тыш, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1)Иске Татар Әмзәсе торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

2) Иске Татар Әмзәсе авылы торак пункты территориясен төзекләндерү (балалар мәйданчыгын сатып алу һәм урнаштыру);

3) су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Иске Рус Әмзәсе торак пунктында ВНБ территориясен киртәләү).

Халык җыенында рәислек итүче: Ә.Ф.Сафиуллина

Әмзә авыл җирлеге башлыгы Ә.Ф.Сафиуллина